Тәүбә

# Милләтнең киләчәге аның тарихына нигезләнгән



Болгардагы Яңа мәчет.

Казан ханлыгы үз мөстәкыйльлеген югалтканнан бирле изге Болгар җирләренә килеп тәүбә итү һәм бабаларыбыз рухына багышлап догалар кылу татарларның изге бер гадәтенә әверелде. Элгәре болар яшерен рәвештә үткәрелсә, соңгы демократик үзгәрешләрдән соң  алар елдан-ел матуррак уздырыла. Ә менә соңгы ике елда халкыбызның үз тарихына һәм ата-бабаларының рухына олы мәхәббәте бигрәк тә ачык күренде. Шулай булмыйча мөмкин дә түгел. Татарлар — Россиянең төп халыклары арасында үз дәүләтчелеге һәм бай тарихы булган бердәнбер милләт. Кызганыч ки, бик күпләр моны аңлый һәм шулар белән горурлана белми.

Болгар җыены — ул халыкны берләштерү, үз милләтенә мәхәббәт һәм горурлык тәрбияләү чарасы. Андагы музейның бай экспозицияләрендә элеккеге заманнарда халкыбызның ничек яшәгәнен ачык күрәсең.

Башка елларда да бирелән без җаннарыбызга рухи байлык туплап кайта идек. Бу җыенның әһәмияте елдан-ел үсүгә без һәрвакыт куанып яшәдек. Ә менә быел мин аннан аеруча хисләргә баеп кайттым.

Халык арасында йөргәндә ике хатын-кызның: «Сөбханалла, монда никадәр бәхетле халык килгән. Бәхетсезләр шул монда килеп йөрми», - дигән сүзләрен ишеткәч, мин моның хакында озак уйланып йөрдем. Милләтебезнең үсешен, уңышларын күреп соклана һәм куана белү - ул үзе зур бәхет бит. Халык күп булса да, бирелә бер генә канәгатьсезлек, усал сүз ишетмисең, ачулы һәм ямьсез караш күрмисең. Һәркемнең йөзендә шатлык балкый, бәйрәм тантанасы ачык күренә.

Болгар - татар тарихының иң затлы, гүзәл һәм үрнәкле бер өлеше - ул Урта Иделдә урнашкан Болгар иле заманы. Кызганыч ки, бүгенге көндә шул Болгар иленең хәрабәләре генә сүзсез шаһитлар булып утырып калганнар. Аллага шөкер, төрле каршылыклар булса да, халыкның бирегә  килеп тәүбә итүе бервакытта да туктамады. Тәүбә итү — ул җан сафлыгын кайгырту рәвеше генә түгел, Аллаһы Тәгаләгә якынаюның иң кыска юлы да.

Туздырып ташланган, мәсхәрәләнгән тарихыбыз бүген бөртекләп җыела һәм торган саен тулылана бара.

Россия Үзәк Диния нәзарәтенең баш мөфтие Тәлгать хәзрәт Таҗетдинның тырышлыгы белән бу җыен торган саен зуррак бәйрәмгә әверелеп бара. Бирелә барган корылышларга, үзгәрешләргә хәйран каласың. Мәсәлән, андагы яңа төзелгән гүзәл мәчет күренеше әле дә күз алдында тора. Ул ап-ак мәрмәр белән төрелгән. Аның нәфис архитектурасына һәм эчендәге сихри гүзәлеккә сокланып туя алмыйсың. Дөньяда иң зурлардан саналган Коръән урнаштырылган бинаның да гүзәллеге искитәрлек.

Кайчандыр бөтен дөньяга даны таралган Болгар шәһәренең туздырылып ташланган хәрабәләре әкрен генә төзекләндерелә бара.

Кызганыч ки, шул торгызылган корылмалар арасында күңелне тырнаучы нәрсәләр дә бар. Болар - чиркәүләр. Әле аларның нигезенә Болгар хәрабәләреннән һәм борынгы каберлекләрдән алынган ташлар кулланганы да билгеле. Бәлки, киләчәктә болар тарихыбызның никадәр җәберләнүен, изелеп тапталуын хәтерләтүче дәһшәтле елларның каһәрле истәлеге булып торырлар.

Болгар тарихының тирән тамырларын өйрәнгәндә аларның җир шарындагы иң борынгы халык икәнен аңлыйсың. Җирдә яшәгән бар халыкта да болгарлар йогынтысы, катнашы бар. Алардан безнең эрага кадәр әтрәчләр (этрусски), трояннар көньяк итальяннар, испаннар, уйгурлар аерылып чыкканнар. Ә безнең эрада — германнар, датчаннар, словаклар, голландлар һәм башка күп халыклар үз илләрен корганнар.

Борынгы заманнарда грек мифологияләре нигезендә күпаллалык киң җәелгәндә, болгарлар бер Аллаһыны гына алга сөрәләр. Хәзер галимнәр болгарларның Мөхәммәт (а.с.) вакытында ук Ислам динен кабул итә башлавын исбатлады. Тарихтан белгәнебезчә, Болгар дәүләтендә төрле халыклар Ислам динен кабул итеп берләшкәннәр һәм дөнья күләмендә танылган дәүләт төзегәннәр.

Болгар тарихы бик тирән, катлаулы һәм гыйбрәтле. Самара шәһәрендә аны пропагандалау өстендә шактый зур эшләр башкарыла. Мәсәлән, «Булгарское наследие» исемле фонд оештырылды. Аның җитәкчесе - Гомәр Батыршин. Бу фонд тарафыннан Зубчаниновка бистәсендә мәчет төзелде. Болгар дәүләтенең көньяк чиге булган Самара Җәясендәге Идел ярында урнашкан Ширяево авылында борынгы Болгар дәүләтенең символы булган стелла куелды. Соңгы вакытта шул темага багышланган «Булгарская цивилизация на Волге» исемле китап басылып чыкты. Аны Фәрид Шириязданов төрле чыганаклардагы мәгълүматларны туплап язды. Бу китапта болгарлар тарихына кагылган кыйммәтле материаллар басылган. Шуңа да аны төрле җыеннарда, Татарстанда үткәрелгән Ислам дине әһелләре форумында зур хөрмәт белән телгә алып, югары бәя бирделәр.



Самара делегациясе Болгар җирендә.

Бу китапның эчтәлеге Болгар темасын пропагандалауга һәм милләтне үстерүгә юнәлгән. Болгар тарихы — ул халкыбызның иксез-чиксез хәзинәсе.

***Фәрид ШИРИЯЗДАНОВ.***

## Июль — Намаз вакытлары — Время намазов

| Число | Иртәнге намаз Фаджр | Кояш чыга Восход | Өйлә намазы Зухр | Икенде намазы Аср | Ахшам намазы Магриб | Ястү намазы Иша | Хиҗри календаре буенча Шаабан |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2:45 | 4:15 | 13:05 | 18:24 | 20:13 | 22:43 | 11 |
| 2 | 2:46 | 4:16 | 13:05 | 18:24 | 21:13 | 22:43 | 12 |
| 3 | 2:47 | 4:17 | 13:05 | 18:24 | 21:12 | 22:42 | 13 |
| 4 | 2:48 | 4:18 | 13:05 | 18:23 | 21:12 | 22:42 | 14 |
| 5 | 2:49 | 4:19 | 13:05 | 18:23 | 21:11 | 22:41 | 15 |
| 6 | 2:50 | 4:20 | 13:05 | 18:23 | 21:11 | 22:41 | 16 |
| 7 | 2:50 | 4:20 | 13:05 | 18:23 | 21:10 | 22:40 | 17 |
| 8 | 2:51 | 4:21 | 13:05 | 18:22 | 21:09 | 22:39 | 18 |
| 9 | 2:52 | 4:22 | 13:05 | 18:22 | 21:09 | 22:39 | 19 |
| 10 | 2:54 | 4:24 | 13:05 | 18:22 | 21:08 | 22:38 | 20 |
| 11 | 2:55 | 4:25 | 13:05 | 18:21 | 21:07 | 22:37 | 21 |
| 12 | 2:56 | 4:26 | 13:05 | 18:21 | 21:06 | 22:36 | 22 |
| 13 | 2:57 | 4:27 | 13:05 | 18:20 | 21:05 | 22:35 | 23 |
| 14 | 2:58 | 4:28 | 13:05 | 18:20 | 21:04 | 22:34 | 24 |
| 15 | 2:59 | 4:29 | 13:05 | 18:19 | 21:03 | 22:33 | 25 |
| 16 | 3:01 | 4:31 | 13:05 | 18:19 | 21:02 | 22:32 | 26 |
| 17 | 3:02 | 4:32 | 13:05 | 18:18 | 21:01 | 22:31 | 27 |
| 18 | 3:03 | 4:33 | 13:05 | 18:18 | 21:00 | 22:30 | 28 |
| 19 | 3:05 | 4:35 | 13:05 | 18:17 | 20:58 | 22:28 | 29 |
| 20 | 3:06 | 4:36 | 13:05 | 18:16 | 20:57 | 22:27 | Рамазан 1 |
| 21 | 3:08 | 4:38 | 13:05 | 18:16 | 20:56 | 22:26 | 2 |
| 22 | 3:09 | 4:39 | 13:05 | 18:15 | 20:54 | 22:24 | 3 |
| 23 | 3:10 | 4:40 | 13:05 | 18:14 | 20:53 | 22:23 | 4 |
| 24 | 3:12 | 4:42 | 13:05 | 18:13 | 20:51 | 22:21 | 5 |
| 25 | 3:13 | 4:43 | 13:05 | 18:12 | 20:50 | 22:20 | 6 |
| 26 | 3:15 | 4:45 | 13:05 | 18:12 | 20:48 | 22:18 | 7 |
| 27 | 3:17 | 4:47 | 13:05 | 18:11 | 20:47 | 22:17 | 8 |
| 28 | 3:18 | 4:48 | 13:05 | 18:10 | 20:45 | 22:15 | 9 |
| 29 | 3:20 | 4:50 | 13:05 | 18:09 | 20:44 | 22:14 | 10 |
| 30 | 3:21 | 4:51 | 13:05 | 18:08 | 20:42 | 22:12 | 11 |
| 31 | 3:23 | 4:53 | 13:05 | 18:07 | 20:40 | 22:10 | 12 |

## Самара өлкәсе Похвистнево районы Гали авылындагы Ислам мәдрәсәсе 2012-2013 елга егетләрне укырга чакыра!

«Гали мәдрәсә»се 1992 елдан алып хәзерге вакытка кадәр имам хатыблар һәм дини белгеч-мөгаллимнәре әзерли.

«Гали мәдрәсә»сенә урта белемле 35 яшькә кадәр булган ир-атлар кабул ителә. Мәдрәсәдә Коръән, Ислам дине кануннары, гарәп теле дәресләре бирелә һәм укуны тәмамлаучыларга имам-хатыб, мөгаллим дәрәҗәсе бирелә. Укыту өчен бирелә бөтен мөмкинчелекләр тудырылган. Дини фәннәрдән тыш дөньяви фәннәрне 9 нчы сыйныфны тәмамлаучылар параллель рәвештә гомуми белем мәктәбендә дә укый алалар. Укуны дәвам итәргә теләүчеләр Уфа шәһәрендәге Рәсәй Ислам Университетына Знче курска керә алачаклар. Мәдрәсәдә уку 2 ел дәвам итә.Укулар 1 сентябрьдән башлана. «Гали мәдрәсә»сен тәмамлаучыларга урта һөнәри дини белем турында таныклык бирелә.

Укырга теләүчеләр мәдрәсә ректоры исеменә гариза язганнан соң кабул итү комиссиясенә 20 августка кадәр түбәндәге документларны алып килүләре мәҗбүри:

1. паспорт күчермәсе;
2. укуны тәмамлаганга таныклык (аттестат яки диплом) күчермәсе;
3. җирле дини оешмадан юллама (направление);
4. гаилә составы белешмәсе (өйләнгәннәргә никах таныклыгы);
5. медицина белешмәсе (ф.086-у);
6. соңгы уку (эш) урыныннан характеристика;
7. 6 фото (3х4).

Белешмәләр өчен адресыбыз һәм телефоннар:

Самара өлкәсе, Похвистнево районы, Гали авылы, Мәктәп урамы 104А.

эл.адресыбыз: **medrese-gali@mail.ru;**

тел./факс: **8 (84656) 20500**-мәдрәсә;

**89277625678** - ректор;

**89270924040** - проректор уку ягыннан.

**Мәдрәсәбезгә укуларга рәхим итегез!**